МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ ______

П Р И К А З　　　　　Б О Е Р Ы К

«____»______________

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча Татарстан Республикасы бюджетына бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 елның 1 декабрендәге 181/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча Татарстан Республикасы бюджетына бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча Татарстан Республикасы бюджетына бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 елның 1 декабрендәге 181/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча Татарстан Республикасы бюджетына бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада)

бирергә.

2. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Җ.Зәйнуллинага) бу боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган вакыттан ун эш көне эчендә аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М.Айзатуллин

Татарстан Республикасы Төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалыгы министрлыгының 2023
елның 1 декабрендәге 181/о
номерлы боерыгы белән расланды

(Татарстан Республикасы Төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалыгы министрлыгының
________________ № ________
боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча Татарстан Республикасы бюджетына бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча Татарстан Республикасы бюджетына бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итүнең әлеге Тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча Татарстан Республикасы бюджетына бурычларны түләтүгә өметсез дип тану процедурасын билгеләү максатларында эшләнде.

2. Министрлык тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

2.1. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче – физик затның үлеме яки аны Россия Федерациясенең гражданлык процессуаль законнары нигезендә үлгән дип игълан итү;

2.2. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 127-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә гражданинның, шәхси эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау – күрсәтелгән Федераль закон нигезендә аларның түләү йөкләмәсен үтәүдән азат ителгән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычлары өлешендә;

2.3. оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле Татарстан Республикасы бюджетына түләнмәгән түләүләр буенча бурычы өлешендә оешма – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче зат бетерелгән очракта;

2.4. штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында актлар кулланылганда яки  бюджет керемнәре администраторы Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча әҗәтләрне түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары кабул ителгәндә, шул исәптән аны түләттерүнең билгеләнгән срогы үтүгә бәйле рәвештә дә;

2.5. «Үтәтү эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 229-ФЗ номерлы федераль закон) 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләтүчегә кире кайтарганда, әгәр бурыч барлыкка килгән көннән бурычлыга карата бөлгенлек турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаса, башкаручы суд приставы тарафыннан башкару эшен тәмамлау турында карар чыгару (бөлгенлек) банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен биш елдан артык вакыт узган булса;

2.6. бюджетка түләүләр түләүче затны банкрот дип тану турында гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты кабул итү;

2.7. теркәүгә ала торган орган тарафыннан юридик зат Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдырылганда һәм, 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча үтәтү документын түләттерүче затка кайтарып, үтәтү эшчәнлеген туктату турында суд пристав-башкаручысы тарафыннан элегрәк чыгарылган карар булганда, – оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле Татарстан Республикасы бюджетына түләнмәгән түләүләр бурычы өлешендә.  «Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә теркәүгә ала торган органның юридик затны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлдә түгел дип танылган очракта, әлеге пунктча нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча элегрәк түләттерү өчен өметсез дип танылган бурычы бюджет (бухгалтерия) исәбендә торгызылырга тиеш.

3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган очраклар белән беррәттән, түләнмәгән административ штрафлар, әгәр административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ җәза билгеләү турындагы карар үтәлешен туктату турында карар чыгарылган булса, түләттерү өчен өметсез дип таныла.

4. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар түбәндәге документлар нигезендә

кабул ителә:

1) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләү буенча бурычларның исәпкә алына торган суммалары турында Министрлык белешмәләре;

2) Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160[1] статьясы нигезендә билгеләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтүнең бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итүдә күрелгән чаралар турында Министрлык белешмәләре;

3) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану очракларын раслаучы документлар, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче – физик затның үлемен раслаучы яки аны үлгән дип игълан итү фактын раслаучы документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктының 2.1 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

конкурс эшчәнлеген тәмамлау яисә шәхси эшкуар булып торган гражданин – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затның мөлкәтен сатуны төгәлләү турында суд акты, шулай ук Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан үзен бөлген (банкрот) дип тану турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә физик зат – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затның шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатуы турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 2.2 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче гражданинның (әлеге Тәртипнең 2 пунктының 2.2 пунктчасында күрсәтелгән очракта) конкурс производствосын тәмамлау яисә мөлкәтен сатуны тәмамлау турында суд акты;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче – оешманы бетерү белән бәйле рәвештә эшчәнлеген туктату турында мәгълүматлар булган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктының 2.3 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы, шул исәптән аны түләтү буенча билгеләнгән срок тәмамлануга бәйле рәвештә дә, Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта торган штраф яки суд акты рәвешендә хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки кичерү турында акт (әлеге Тәртипнең 2 пунктының 2.4 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча (әлеге Тәртипнең 2 пунктының 2.5, 2.6 пунктчаларында күрсәтелгән очракларда, әлеге Тәртипнең 2 пунктының 6 пунктчасында күрсәтелгән очракта) җәзага тартылучыга башкарма документ кайтарылу белән бәйле рәвештә башкарма производствоны тәмамлау турында суд пристав-башкаручысы карары;

бюджетка түләүләр түләүче затны бөлген (банкрот) дип тану турында

гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 2.6 пункчасының өченче абзацында күрсәтелгән очракта);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче юридик затны теркәү органы карары буенча күрсәтелгән реестрдан чыгару турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар булган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 2.7 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турында карар (әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән очракта);

гражданинның судтан тыш банкротлык процедурасы тәмамлануы турында Банкротлык турындагы белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктының 2.2 пунктчасында күрсәтелгән очракта).

5. Бурычны түләтүгә өметсез дип тану эшен оештыру максатларында комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары һәм комиссия әгъзалары составында Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны исәптән чыгару комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә. Комиссиянең саны алты кеше тәшкил итә. Комиссиянең шәхси составы министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – министр) боерыгы белән раслана.

Комиссияне Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүче рәис җитәкли. Рәис булмаганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

6. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма елына кимендә бер тапкыр үткәрелә.

7. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану нигезләрен раслаучы документлар җыелмасы әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә Министрлыкның керемнәрнең тиешле административ чыганагы беркетелгән структур бүлекчәсе тарафыннан әлеге Тәртипнең 2 яисә 3 пунктында каралган очрак килеп чыгу турында Министрлыкка мәгълүмат кергән вакыттан алып утыз календарь көн эчендә төзелә һәм Комиссиягә карау өчен җибәрелә.

8. Комиссия Министрлыкның әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән керемнәрнең тиешле административ чыганагы беркетелән структур бүлекчәсе тәкъдим иткән документларны алар Комиссиягә кергән көннән алып унбиш эш көне дәвамында карап тикшерә.

9. Комиссия карарны ачык тавыш бирү юлы белән аның әгъзалары санының гади күпчелек тавышлары белән кабул итә. Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының яртысыннан артыграгы катнашса, Комиссия карары тулы хокуклы дип санала. Тавышлар тигез булганда, Комиссия утырышында

рәислек итүченең тавышы хәл итүче дип санала.

Комиссия утырышы беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Комиссия әгъзалары кул куя. Беркетмәне рәсмиләштерү срогы Комиссия утырышын уздырган көннән алып биш эш көне тәшкил итә.

10. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану мәсьәләсен карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) әлеге Тәртипнең 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән нигезләр һәм (яки) әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар булганда, Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танырга;

2) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танымаска – әлеге Тәртипнең 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән нигез һәм әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар булмаганда. Әлеге карар Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану мәсьәләсен кабат карауга комачауламый.

11. Комиссия утырышы йомгаклары буенча, Тәртипнең 10 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очракта, утырыш уздырылган көннән алып ун эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар проекты әзерләнә.

12. Комиссия карары Комиссия утырышын уздырган көннән алып ун эш көне эчендә түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган акт белән рәсмиләштерелә:

1) оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта));

2) салым түләүченең идентификацияләү номеры, төп дәүләт теркәвенә алу номеры, салым түләүченең оешмасын исәпкә алуның сәбәп коды (физик затның салым түләүчесенең идентификацияләү номеры) (булган очракта));

3) бурычны барлыкка китергән түләү турында белешмәләр;

4) аның буенча Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч исәпкә алына торган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен классификацияләү коды, аның исеме;

5) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычлар суммасы;

6) Татарстан Республикасы бюджетына тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

7) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул ителгән көн;

8) Комиссия әгъзаларының имзалары.

Акт ике нөсхәдә төзелә һәм утырышта рәислек итүче һәм утырышта булган Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

13. Комиссия тарафыннан рәсмиләштерелгән акт имзаланган көннән алып биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры тарафыннан раслана.

14. Тәртипнең 10 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очракта, комиссия утырышы беркетмәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану өчен нигезләр булмау турындагы мәгълүмат чагылдырыла. Беркетмә утырышта рәислек итүче һәм Комиссия секретаре тарафыннан имзалана һәм министрга хәбәр итү өчен җибәрелә.